КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 29 декабрь г.Казань № 1081

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 – 2019 елларда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планын раслау турында» 2016 ел, 8 октябрь, 729 нчы карары белән расланган 2017 – 2019 елларда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 – 2019 елларда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы

карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планын раслау турында» 2016 ел, 8 октябрь, 729 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2017 ел, 28 февраль, 118 нче, 2017 ел, 21 март, 161 нче; 2017 ел, 27 сентябрь, 730 нчы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган 2017 – 2019 елларда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планына (алга таба – Кыска вакытлы план) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Кыска вакытлы планның төп максатлары һәм бурычлары

Кыска вакытлы планның төп максатлары:

Татарстан Республикасында торак фондын саклау, торгызу һәм аның сыйфатын күтәрү;

гражданнарның яшәве өчен имин һәм уңай шартлар тудыру;

күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүгә дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм күрсәтү.

Кыска вакытлы планның төп бурычлары:

халык белән актив агитация-аңлату эшләре үткәрү;

капиталь ремонт үткәргәндә, озакка чыдам материаллар һәм ресурслар саклый торган технологияләр кулланып, нәтиҗәле техник чишелешләрдән һәм комплекслылыктан файдалану.

Кыска вакытлы планны тормышка ашыру вакыты: 2017 – 2019 еллар.

2017 елда Кыска вакытлы планны тормышка ашыру 230 232 гражданга 6,5 млн.кв.метр гомуми мәйданлы 982 күпфатирлы йортта имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш.

Кыска вакытлы планга 8,1 млн.кв.метр гомуми мәйданлы 931 күпфатирлы йортка шәхси җылылык пунктлары (ШҖП) җиһазын һәм, булганда, күтәрүче насос җайланмаларын комплекста урнаштыруга проект документларын эшләү һәм капиталь ремонтлау үткәрүе 2018 елга планлаштырылган 645,5 мең кв.метрлы гомуми мәйданлы күпфатирлы йортларга проект документларын эшләү кертелә.

2018 елда Кыска вакытлы планны тормышка ашыру 224 298 гражданга 5,3 млн.кв.метр гомуми мәйданлы 984 күпфатирлы йортта имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш.

Кыска вакытлы планга капиталь ремонт үткәрүе 2019 елда планлаштырылган 1 000,1 мең кв.метр гомуми мәйданлы 159 күпфатирлы йортка проект документларын эшләү кертелә.

2019 елда Кыска вакытлы планны тормышка ашыру 218 437 гражданга 5,5 млн.кв.метр гомуми мәйданлы 1020 күпфатирлы йортта имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш.

Кыска вакытлы планга капиталь ремонт үткәрүе 2020 елда планлаштырылган 580,9 мең кв.метр гомуми мәйданлы 121 күпфатирлы йортка проект документларын эшләү кертелә.

Кыска вакытлы планны үтәү буенча планлаштырыла торган күрсәткечләр түбәндәгеләрдә китерелә:

Татарстан Республикасы буенча тулаем алганда Кыска вакытлы планга теркәлгән 1 нче кушымтада;

Кыска вакытлы планны үтәүдә катнашучы муниципаль берәмлекләр яктылыгында әлеге планга теркәлгән 2 нче кушымтада.»;

IV бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IV. Кыска вакытлы планны үтәү буенча планлаштырыла торган күрсәткечләр

2017 – 2019 елларда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрү күләмнәре

| Т/с | Күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эш күләме | Шул исәптән: | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | Түбә төзәтү, шул исәптән җылләтелми торган түбәне җылләтелә торган түбә итеп үзгәртү, түбәгә чыгу урыннарын ясау | мең кв.метр | 1 232,7 | 474,9 | 416,8 | 341,0 |
| 2. | Йорт эчендәге электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итә, суны читкә агызып чыгара торган инженерлык системаларын төзәтү яки алыштыру, шул исәптән торак урыннардагы җылыту элементларын, шулай ук йорт эчендәге инженерлык системаларында урнашкан механик, электр, санитар-техник җайланмаларны төзәтү яки алыштыру, шул исәптән: | мең метр | 3 923,0 | 1 064,1 | 1 638,7 | 1 220,2 |
| 2.1. | электр белән тәэмин итү | мең метр | 1 269,4 | 279,2 | 488,4 | 501,8 |
| 2.2. | җылылык белән тәэмин итү | мең метр | 1 330,0 | 357,4 | 575,5 | 397,1 |
| 2.3. | су белән тәэмин итү | мең метр | 870,3 | 289,0 | 382,6 | 198,7 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.4. | суны читкә агызып чыгару | мең метр | 453,1 | 138,5 | 192,0 | 122,6 |
| 2.5. | газ белән тәэмин итү | мең метр | 0,2 | 0,0 | 0,2 | 0,0 |
| 3. | Коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле ресурслар (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, электр энергиясе, газ) куллануны исәпкә алуның күмәк (гомумйорт) приборларын урнаштыру | данә | 111 | 27 | 37 | 47 |
| 4. | Җылылык энергиясен куллану белән идарә итү узелларын һәм җайга салу узелларын урнаштыру | данә | 543 | 158 | 153 | 232 |
| 5. | Эксплуатацияләү өчен ярак-сыз дип танылган лифт җайланмасын алыштыру | данә | 937 | 300 | 312 | 325 |
| 6. | Лифт шахталарын төзәтү | данә | 19 | 2 | 2 | 15 |
| 7. | Күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә караган подвал урыннарын төзәтү | мең кв.метр | 160,1 | 68,5 | 37,2 | 54,4 |
| 8. | Бинаның алгы ягын төзәтү, күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтнең халыкның аз мобиль төркемнәре өчен файдаланырлык булуын тәэмин итү максатларында подъездларның керү төркемнәрен пандуслар һәм баскычларны ике яктан рәшәткәләр белән җиһазлау | мең кв.метр | 3 056,8 | 930,3 | 1 250,0 | 876,5 |
| 9. | Бинаның алгы ягын җылыту, күпфатирлы йортта уртак мөлкәтнең халыкның аз мобиль төркемнәре өчен файдаланырлык булуын тәэмин итү максатларында подъездларның керү төркемнәрен пандуслар һәм баскычларны ике яктан рәшәткәләр белән җиһазлау | мең кв.метр | 89,4 | 3,4 | 83,1 | 2,9 |
| 10. | Күпфатирлы йорт нигезен төзәтү | мең куб.метр | 6,9 | 0,6 | 0,8 | 5,5 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 11. | Күпфатирлы йортка энергетик тикшерү үткәрү | данә | 520 | 147 | 226 | 147 |
| 12. | Күпфатирлы йортларга техник инвентаризация үткәрү эшләрен башкару һәм техник паспортлар ясау | данә | 1 774 | 638 | 677 | 459 |
| 13. | Күпфатирлы йорттагы подъездларны төзәтү | мең кв.метр | 597,4 | 195,1 | 213,4 | 188,9 |
| 14. | Күпфатирлы йортны янгыннан саклау системасын төзәтү | мең кв.метр | 41,2 | 6,0 | 26,2 | 9,0 |
| 15. | Төзелеш тикшерүендә тотуны гамәлгә ашыру | данә | 2 996 | 981 | 995 | 1 020 |
| 16. | Капиталь ремонтлау үткәрүе 2017 елга планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документларын эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләүнең дөреслегенә тикшерү үткәрү | данә | 1 719 | 1 719 | 0 | 0 |
| 17. | Капиталь ремонтлау үткәрүе 2018 елга планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документларын эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләүнең дөреслегенә тикшерү үткәрү | данә | 996 | 131 | 865 | 0 |
| 18. | Капиталь ремонтлау үткәрүе 2019 елга планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документларын эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләүнең дөреслегенә тикшерү үткәрү | данә | 856 | 0 | 155 | 701 |
| 19. | Капиталь ремонтлау үткәрүе 2020 елга планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документларын эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләүнең дөреслегенә тикшерү үткәрү | данә | 121 | 0 | 0 | 121 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 20. | Шәхси җылылык пунктлары (ШҖП) җиһазын һәм, булганда, күтәрүче насос җайланмаларын комплекста урнаштыру | данә | 998 | 0 | 998 | 0 |

Кыска вакытлы планга кертелгән ремонт төрләре буенча күпфатирлы йортлар реестры әлеге планга теркәлгән 3 нче кушымтада китерелә.»;

V бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V. Ресурслар белән тәэмин итү

Кыска вакытлы планны финанслау чыганаклары булып Татарстан Республикасы бюджеты һәм (яки) җирле бюджетлар, торак милекчеләре ширкәтләре, торак кооперативлары, торак-төзелеш кооперативлары (алга таба – шул ук эзлеклелектә ТМШ, ТК, ТТК) яки бүтән махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары әгъзалары яисә күпфатирлы йортлардагы бүлмәләр милекчеләре акчасы тора.

Кыска вакытлы план чараларын финанслауның гомуми күләме 17 191 775 134,71 сум тәшкил итә, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 4 075 351 989,02 сум;

җирле бюджетлар акчасы – 3 219 938 015,75 сум;

ТМШ, ТК, ТТК яки бүтән махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары әгъзалары яисә күпфатирлы йортлардагы бүлмәләр милекчеләре акчасы – 9 246 485 129,94 сум;

заем – 650 000 000,00 сум.

Шулардан:

2017 елда:

Кыска вакытлы план чараларын финанслауның гомуми күләме 4 716 192 006,01 сум тәшкил итә, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 1 346 800 589,02 сум;

җирле бюджетлар акчасы – 791 449 610,12 сум;

ТМШ, ТК, ТТК яки бүтән махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары әгъзалары яисә күпфатирлы йортлардагы бүлмәләр милекчеләре акчасы – 2 577 941 806,87 сум;

2018 елда:

Кыска вакытлы план чараларын финанслауның гомуми күләме 7 207 722 885,19 сум тәшкил итә, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 1 364 275 700,00 сум;

җирле бюджетлар акчасы – 1 355 557 405,63 сум;

ТМШ, ТК, ТТК яки бүтән махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары әгъзалары яисә күпфатирлы йортлардагы бүлмәләр милекчеләре акчасы – 3 837 889 779,56 сум;

заем – 650 000 000,00 сум;

2019 елда:

Кыска вакытлы план чараларын финанслауның гомуми күләме 5 267 860 243,51 сум тәшкил итә, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 1 364 275 700,00 сум;

җирле бюджетлар акчасы – 1 072 931 000,00 сум;

ТМШ, ТК, ТТК яки бүтән махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары әгъзалары яисә күпфатирлы йортларда бүлмәләр милекчеләре – 2 830 653 543,51 сум.

Бу очракта Кыска вакытлы планны тормышка ашыру кысаларында Кыска вакытлы планны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның 50 проценты ел саен энергия саклау буенча эшләр башкаруга җибәрелә.

Шәхси җылылык пунктлары (ШҖП) җиһазын һәм, булганда, күтәрүче насос җайланмаларын комплекста урнаштыру чараларын финанслау күләме 2018 елда 932 688 405,63 сум тәшкил итәчәк, шул исәптән 650 000 000,00 сумы – Төбәк операторының Попечительләр советы ризалыгы белән «Татарстан Республикасының Торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы тарафыннан җәлеп ителгән заем акчасы. Заем һәм заемнан файдаланган өчен процент түләүне финанслау күләме 2018 – 2022 елларда 785 170 432,92 сум тәшкил итәчәк.

2017 – 2019 елларда күпфатирлы йортларга
капиталь ремонт үткәрүгә финанс чаралары күләме

| Т/с | Күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яки) эшләр башкару исемлеге | Суммасы, млн.сум | Шул исәптән | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | Түбә төзәтү, шул исәптән җилләтелми торган түбәне җилләтелә торган түбә итеп үзгәртү, түбәгә чыгу урыннарын ясау | 3 248,2 | 1 120,6 | 1 155,7 | 971,9 |
| 2. | Йорт эчендәге электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итә, суны читкә агызып чыгара торган инженерлык системаларын төзәтү яки алыштыру, шул исәптән торак урыннардагы җылыту элементларын, шулай ук йорт эчендәге инженерлык системаларында урнашкан механик, электр, санитар-техник җайланмаларны төзәтү яки алыштыру, шул исәптән: | 5 236,9 | 1 439,2 | 2 039,5 | 1 758,2 |
| 2.1. | электр белән тәэмин итү | 666,6 | 146,9 | 223,9 | 295,8 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 2.2. | җылылык белән тәэмин итү | 2 596,3 | 695,8 | 1 024,2 | 876,3 |
| 2.3. | су белән тәэмин итү | 1 183,6 | 366,4 | 463,7 | 353,5 |
| 2.4. | суны читкә агызып чыгару | 787,9 | 230,1 | 325,2 | 232,6 |
| 2.5. | газ белән тәэмин итү | 2,5 | 0,0 | 2,5 | 0,0 |
| 3. | Коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле ресурслар (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, электр энергиясе, газ) куллануны исәпкә алуның күмәк (гомумйорт) приборларын урнаштыру | 16,4 | 9,5 | 2,5 | 4,4 |
| 4. | Җылылык энергиясен куллану белән идарә итү узелларын һәм аны җайга салу узелларын урнаштыру | 327,0 | 82,6 | 98,8 | 145,6 |
| 5. | Эксплуатация өчен яраксыз дип танылган лифт җайланмасын алыштыру | 1 759,7 | 493,0 | 608,1 | 658,6 |
| 6. | Лифт шахталарын төзәтү | 2,1 | 0,1 | 0,3 | 1,7 |
| 7. | Күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә караган подвал урыннарын төзәтү | 90,9 | 20,1 | 25,9 | 44,9 |
| 8. | Бинаның алгы ягын төзәтү, күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтнең халыкның аз мобиль төркемнәре өчен файдаланырлык булуын тәэмин итү максатларында подъездларның керү төркемнәрен пандуслар һәм баскычларны ике яктан рәшәткәләр белән җиһазлау | 3 797,3 | 1 164,9 | 1 440,6 | 1 191,8 |
| 9. | Бинаның алгы ягын җылыту, күпфатирлы йортта уртак мөлкәтнең халыкның аз мобиль төркемнәре өчен файдаланырлык булуын тәэмин итү максатларында подъездларның керү төркемнәрен пандуслар һәм баскычларны ике яктан рәшәткәләр белән җиһазлау | 205,4 | 10,9 | 187,2 | 7,3 |
| 10. | Күпфатирлы йорт нигезен төзәтү | 16,0 | 2,9 | 3,2 | 9,9 |
| 11. | Күпфатирлы йортка энергетик тикшерү үткәрү | 14,0 | 4,4 | 5,4 | 4,2 |
| 12. | Күпфатирлы йортларга техник инвентаризация үткәрү эшләрен башкару һәм техник паспортлар ясау | 85,5 | 28,4 | 35,5 | 21,6 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 13. | Күпфатирлы йорттагы подъездларны төзәтү | 496,1 | 131,5 | 261,9 | 102,7 |
| 14. | Күпфатирлы йортны янгыннан саклау системасын төзәтү | 22,0 | 7,9 | 10,9 | 3,2 |
| 15. | Төзелеш тикшерүендә тотуны гамәлгә ашыру | 153,6 | 46,9 | 57,7 | 49,0 |
| 16. | Капиталь ремонтлау үткәрүе 2017 елга планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документларын эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләүнең дөреслегенә тикшерү үткәрү | 67,0 | 67,0 | 0,0 | 0,0 |
| 17. | Капиталь ремонтлау үткәрүе 2018 елга планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документларын эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләүнең дөреслегенә тикшерү үткәрү | 128,2 | 34,1 | 94,1 | 0,0 |
| 18. | Капиталь ремонтлау үткәрүе 2019 елга планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документларын эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләүнең дөреслегенә тикшерү үткәрү | 107,8 | 0,0 | 42,3 | 65,5 |
| 19. | Капиталь ремонтлау үткәрүе 2020 елга планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документларын эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләүнең дөреслегенә тикшерү үткәрү | 30,1 | 0,0 | 0,0 | 30,1 |
| 20. | Комплекста шәхси җылылык пунктлары (ШҖП) җиһазын һәм, булганда, күтәрүче насос җайланмаларын комплекста урнаштыру | 991,6 | 52,2 | 939,4 | 0,0 |
| 20.1. | заем акчасы исәбеннән | 650,0 | 0,0 | 650,0 | 0,0 |
| 20.2. | проект документларын эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләүнең дөреслегенә тикшерү үткәрү | 52,2 | 52,2 | 0,0 | 0,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 21. | Җәлеп ителгән заемны түләү | 289,8 | 0,0 | 124,2 | 165,6 |
| 22. | Заемнан файдаланган өчен процент түләү | 106,2 | 0,0 | 74,5 | 31,7 |
| 23. | Ресурслардан файдалануны җайга салу узелларын урнаштыру (бары тик ТМИ, ТК, ТТК яки бүтән махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары әгъзалары яисә күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре акчасы исәбеннән, бу чакта ресурслардан файдалануны җайга салу узелларын урнаштыруны финанслау 2014 елдан 2019 елга кадәрге чорда еллык кыска вакытлы планнар һәм төзелгән шартнамәләр нигезендә гамәлгә ашырыла) | 408,9 | 86,9 | 86,6 | 39,9 |
| 24. | Күпфатирлы йортларда 2014 елның 1 июненә кадәрге чорда урнаштырылган (алыштырылган) күмәк (гомумйорт) коммуналь ресурслардан файдалануны исәпкә ала торган җайланмаларны урнаштыру (бары тик ТМИ, ТК, ТТК яки бүтән махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары әгъзалары яисә күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре акчасы исәбеннән) | 68,4 | 53,2 | 11,4 | 3,8 |
| | Барлыгы* | 17 191,8 | 4 716,2 | 7 207,7 | 5 267,9 |

*Ресурслардан файдалануны җайга салу узелларын урнаштыруга (бары тик ТМИ, ТК, ТТК яки бүтән махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары әгъзалары яисә күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре акчасы исәбеннән генә, бу чакта ресурслардан файдалануны җайга салу узелларын урнаштыруны финанслау 2014 елдан 2019 елга кадәрге чорда еллык кыска вакытлы планнар һәм төзелгән шартанмәләр нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм күпфатирлы йортларда 2014 елның 1 июненә кадәр урнаштыру (алмаштыру) гамәлгә ашырылган коммуналь ресурслардан файдалануны исәпкә ала торган күмәк (гомумйортта) приборларын урнаштыруга (алмаштыруга) (бары тик ТМИ, ТК, ТТК яки бүтән махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары әгъзалары яисә күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре акчасы исәбеннән генә) финанс чараларына булган ихтыяҗ күләмнәрен исәпкә алмыйча.

ТМИ, ТК, ТТК яки бүтән махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары әгъзалары яисә күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре акчасы исәбеннән генә ресурслардан файдалануны җайга салу узелларын урнаштыруны финанслау вакытлары Кыска вакытлы планга теркәлгән 4 нче кушымтада китерелә.

Капиталь ремонт үткәрү кыйммәтен күрсәтеп, күпфатирлы йортлар исемлеге Кыска вакытлы планга теркәлгән 5 нче кушымтада китерелә.

ТМИ, ТК, ТТК яки бүтән махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары әгъзалары яисә күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре акчасы исәбеннән күпфатирлы йортларда коммуналь ресурслардан файдалануны исәпкә ала торган күмәк (гомумйорт) приборларын урнаштыруны (алмаштыруны) финанслау күләме Кыска вакытлы планга теркәлгән 6 нчы кушымтада китерелә.

Проект документларын эшләү һәм комплекста шәхси җылылык пунктлары (ШҖП) җиһазларын һәм, булганда, күтәрүче насос җайланмаларын комплекста урнаштыруга смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерү үткәрү буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яки) эшләр башкару кыйммәтен күрсәтеп, күпфатирлы йортлар һәм финанслау чыганаклары исемлеге Кыска вакытлы планга 7 нче кушымтада китерелә.

Төбәк операторы тарафыннан шәхси җылылык пунктлары (ШҖП) җиһазларын һәм, булганда, күтәрүче насос җайланмаларын комплекста урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яки) эшләр башкару максатларында җәлеп ителгән заем акчаларын түләү вакыты һәм чыганагы Кыска вакытлы планга 8 нче кушымтада китерелә.»;

VI бүлектә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2017 – 2019 елларга күпфатирлы йорттагы урыннарның гомуми мәйданының 1 кв.метрга исәпләгәндә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләменнән чыгып формалаштырылган капиталь ремонт фонды акчасы исәбеннән Төбәк оператор тарафыннан түләнә ала торган күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яки) эшләр башкаруның иң чик кыйммәте күләме 14 мең сум тәшкил итә.»;

VII бүлектә:

утыз бишенче абзацта «Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә һәм» төшереп калдырырга;

Кыска вакытлы планга теркәлгән 1 – 3, 5 – 7 нче кушымталарны (карарга теркәләләр) яңа редакциядә бәян итәргә;

Кыска вакытлы планга теркәлгән 8 нче кушымтада:

741 – 744 нче пунктларда 2 графада «Мамадыш тракты урамы» сүзләрен «Мамадыш Тракты урамы» сүзләренә алыштырырга.

2. Бу карар белән кертелгән үзгәрешләр өлешендә күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау 2017 елдан 2018 елга кадәр гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин